ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**17.09.2025** **Чистай шәһәре** **№ 460**

Үзгәртеп оештыру турында

«Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» ФЗ, Россия Федерациясенең 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Граждан кодексы белән бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү, матди-техник ресурслардан нәтиҗәле файдалану һәм белем бирү процессы белән идарә итүнең оптималь системасын булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең 2025 елның 29 августындагы 1 номерлы гражданнар җыены карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырырга (алга таба-үзгәртеп оештыру).
2. Үзгәртеп оештыруны әзерләү һәм үткәрү буенча җаваплылыкны, шулай ук үзгәртеп оештыру турында белешмәләрне теркәүче органга бирү бурычларын, шул исәптән хәбәрнамәгә, гаризага һәм үзгәртеп оештыру процедурасын рәсмиләштерү өчен кирәкле башка документларга имза хокукы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Мирсияпова Гөлкәй Әнәс кызына йөкләргә.
3. Үзгәртеп оештыру процедурасы турында хәбәрнамәне «Дәүләт теркәве хәбәрләре» журналында айга бер тапкыр ешлык белән ике тапкыр, юридик затларның эшчәнлеге фактлары турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрында (Федресурс) урнаштырган өчен, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru урнаштырган өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Мирсияпова Гөлкәй Әнәс кызына йөкләргә.
4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру буенча чаралар планын һәм комиссия составын Татарстан Республикасы

Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә әлеге карарга кушымта нигезендә (1,2 нче кушымта) расларга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6.Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Н.А. Карманова) акчаларның максатчан файдаланылуын тикшереп торуны тәэмин итәргә.
7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы (О.В.Купцова) өстенә йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.09.2025 № 460
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә «Татар Талкышы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениесен үзгәртеп оештыру чаралары планы**

| т/б | Чаралар исеме | Чараларны башкару срогы |
|---|---|---|
| 1. | Юридик затларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы вәкаләтле дәүләт органын үзгәртеп оештыру процедурасы башлану турында язма рәвештә хәбәр итәргә | Үзгәртеп оештыру турында карар кабул итү датасыннан соң өч эш көне эчендә |
| 2. | Юридик затларны дәүләт теркәве турында белешмәләр басылып чыккан массакүләм мәгълүмат чараларында айга бер тапкыр тапкыр үзгәртеп оештыру турында хәбәрнамә урнаштырырга | Үзгәртеп оештыру турында карар кабул ителгән көннән соң биш эш көне эчендә |
| 3. | Яңадан оештырыла торган учреждениенең танылган кредиторларын үзгәртеп кору башлануы турында хәбәр итәргә | Теркәлүче органга үзгәртеп оештыру процедурасын башлау турында хәбәр җибәрү датасыннан соң биш эш көне дәвамында |
| 4. | Тапшырыла торган активларга һәм бурычларга инвентарьлаштыру уздырырга, кушылу рәвешендә үзгәртеп корганда бухгалтерлык (финанс) хисабын төзергә | Теркәлүче органга үзгәртеп оештыру процедурасын башлау турында хәбәр җибәрү датасыннан соң биш эш көне дәвамында |
| 5. | Кушылу гамәлгә ашырыла торган учреждение урнашкан урын буенча теркәү органына кушылган юридик затның эшчәнлеген туктату турында язма кертү хакында гариза тапшырырга | Юридик затларны үзгәртеп оештыру турындагы хәбәр «Дәүләт теркәве хәбәрләре» журналында икенче тапкыр басылып чыккан көннән соң 30 көн узгач |

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.09.2025 № 460
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә «Татар Талкышы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениесен үзгәртеп оештыру буенча комиссия составы**

**Комиссия рәисе:**

1.Хәсәнов Э.Р. - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

**Комиссия рәисе урынбасары:**

2.Купцова О.В. - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары һәм «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы.

**Комиссия секретаре:**

3.Мирсияпова Г.А. - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры.

**Комиссия әгъзалары:**

4.Исхакова М.Ю. - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча);

5.Карманова Н.А.-Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе (килешү буенча);

6.Сафина Г.Ф.- «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары;

7.Галиуллина В.В. - «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчесе.